**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 сентябрь № 638

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш кирәк-яракларының һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш кирәк-яракларының һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 ел, 15 ноябрь, 832 нче; 2002 ел, 25 октябрь, 625 нче; 2003 ел, 4 апрель, 179 нчы; 2004 ел, 17 май, 239 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 724 нче; 2010 ел, 17 август, 661 нче; 2012 ел, 25 сентябрь, 800 нче; 2016 ел, 31 март, 192 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка «утлы» сүзеннән соң «, зарарлавы чикләнгән утлы корал,» сүзләрен өстәргә;

карарның 5 нче пункты үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Гражданнардан түләүсез нигездә корал, сугыш кирәк-яраклары һәм шартлаткыч матдәләр кабул итү эшен оештыру турындагы нигезләмәдә:

2 нче һәм 3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аларда саклаңган (шул исәптән эчке эшләр органнарының тиешле рөхсәтеннән башка) коралны, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлату җайланмаларын үз теләге белән тапшырган затларга, әгәр аларның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, әлеге Нигезләмәнең 5 нче пунктында билгеләнгән күләмдә акчалата түләү бирелә.

3. Аңарда саклаңган (шул исәптән эчке эшләр органнарының тиешле рөхсәтеннән башка) коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм шартлаткыч матдәләрне

түләүле нигездә тапшыру теләген белдергән граждан Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы буйсынуындагы Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының теләсә кайсы район дәрәҗәсендәге территориаль органына үз сайлавы буенча мөрәҗәгать итә. Бу вакытта мөрәҗәгатьнең конфиденциальлеге саклана.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.1 нче пункт өстәргә:

«3.1. Гражданнар тарафыннан эчке эшләр органнарына үз теләкләре белән бирелгән сырлы көпшәле утлы корал Россия ЭЭМ норматив хокукый актлары нигезендә тикшерү өчен атып каралырга тиеш.»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Законсыз сакланган коралны, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне үз теләге белән тапшырган затларга, әгәр аларның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, түбәндәге күләмдә акчалата түләү бирелә:

а) сырлы көпшәле утлы корал өчен 3000 сум;

б) шартлаткыч матдәләр (тротил, аммонит һ.б.) һәм шартлату чаралары (детонаторлар, утүткәргеч чыбык һ.б.) өчен 2000 сум, ләкин базар кыйммәтеннән арттырмыйча;

в) кабызгыч сугыш гранаталары һәм шома көпшәле утлы ау коралы өчен 1500 сум;

г) көпшәсе киселгән мылтыклар һәм кулдан ясалган утлы корал өчен 1000 сум;

д) пневматика (3 Дж югары), газ коралы һәм зарарлавы чикләнгән утлы корал өчен 500 сум;

е) сырлы көпшәле утлы коралга сугыш кирәк-яраклары өчен 20 сум.

Законсыз сакланган корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр, шартлату җайланмалары турында дөрес мәгълүмат биргән өчен әлеге пунктта коралның, сугыш кирәк-яракларының, шартлаткыч матдәләрнең, шартлату җайланмаларының аерым бер төре өчен билгеләнгән сумманың 50 проценты күләмендә акчалата түләү бирелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 9 нчы пункт өстәргә:

«9. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына ике ай эчендә корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр һәм шартлату җайланмалары тапшырган гражданнарга акчалата түләү бирүне регламентлаштыра торган тәртипне эшләргә һәм расларга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков